**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советының**

**КАРАРЫ**

**2018 ел, 14 ноябрь** **№ 97**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 4 августындагы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмә хакында” 58нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 4 августындагы 58нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлегенә белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, съездда (конференция) яисә башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләре гомуми җыелышында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш;

муниципаль берәмлеге исеменнән оешма оештыручы һәм мунципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлары нигезендә оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оештыручы (акционер, катнашучы) булган муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш; федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;".

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы, Совет ур., 11 йорт (үзидарә);

- шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы, К.Маркс ур., 105 йорт, китапханә, уку залы, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

"Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогы"
муниципаль берәмлеге Башлыгы уранбасары,
Советы рәисе урынбасары В.П. Сороковнин